ӨЛКӘ MASSA KITAPXANƏSE
ОСНОВНОЕ КНИГОХРАНИЛИЩЕ ОБЛАСТНОЙ МАССОВОЙ ЛЕНИНА БИБЛИОТЕКИ АТССР г. Казань

ҖОМГА
1 МАРТ
1940 ел
№ 50 (5850)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—73, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

Өч республика ярышы

Шушы елның январь аенда Татарстан авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика киңәшмәсе, орденлы республикабызның барлык колхозчылары, совхоз һәм МТС эшчеләре, авыл хуҗалыгы белгечләре исменнән, күрше ике республика белән—автономияле орденлы Чувашстан һәм Мордовия республикалары белән 1940 нчы елда югары иген уңышы алу, социалистик терлекчелекне үстерү буенча социалистик ярышка чыкты һәм Татарстан республикасы өчен төп күрсәткечләрне билгеләп социалистик ярыш договорына кул куелды.

Социалистик ярыш договоры Чувашстанның һәм Мордовиянең авыл хуҗалыгы алдынгылары киңәшмәләрендә февраль аенда тикшерелеп кабул ителде һәм рәсмиләштерелде.

Без газетабызның бүгенге номерында өч республика ярышы буенча шул договорны урнаштырабыз.

Кардәш өч республика арасында төзелгән бу договор Сталинчыл югары иген уңышы алу, социалистик терлекчелекне тагын да үстерү буенча республикабызның барлык хезмәт ияләренә гаять зур бурычлар йөкли. Договорда күрсәтелгән йөкләмәләрне тулысынча үтәү һәм арттырып үтәү өчен көрәш—барлык колхозчыларның, совхоз, МТС һәм җир органнары работникларының намус эше!

Өч республика арасында оештырылган социалистик ярыш алдынгыларының уңышлы тәҗрибәләрен башкаларга күчерү, артта калучыларга конкрет булышлык оештыру нигезендә Татарстанда иген уңышын күтәрүдә кискен борылыш ясау өчен һәм социалистик терлекчелек буенча дәүләт планын арттырып үтәү өчен массаны туплауда иң зур корал булырга тиеш. „Социалистик ярыш әйтә: берәүләр начар эшли, икенчеләр яхшы, өченчеләр яхшырак,—яхшыларны куып җит һәм гомуми күтәрелешкә иреш“ (Сталин).

Социалистик ярышта җиңеп чыгу өчен көрәштә язгы чәчүгә большевистик хәзерлекне тәэмин итү хәл иткеч шартларның берсе икәнлеге һәр кемгә билгеле. Шуңа күрә дә язгы чәчүгә үрнәк рәвештә хәзерләнү договор буенча алган йөкләмәләребезнең тормышка ашырылуына ирешүнең беренче этапы булырга тиеш.

Республикабызда язгы чәчүгә хәзерлек эше ничек тора соң? Бөтен ачыклыгы белән әйтергә кирәк: һич тә канәгатьләнерлек тормый әле. Моның шулай икәнлеген трактор паркының 25 нче февральгә бары 63,9 процент ремонтлануы, механизатор кадрлар хәзерләү эшенең торышы әле дә кирәкле дәрәҗәдә булмавы, чәчү орлыгын туплау һәм аны тиешле кондициягә китерү эшенең гафу ителмәслек дәрәҗәдә акырын баруы ачык күрсәтәләр.

Тракторларга ремонт ясауда Чокалы, Мөрәле, Зөя, Тельман, Үзәк МТС лары аеруча начар эшләгәнлекне әйтеп үтәргә кирәк. Боларда ремонт планы өзелү куркынычы алдында тора. Үтәлеш бары 29—34 процент кына. Бу МТС ларның җитәкчеләре ремонт эшендә җавапсызлык күрсәтүләрендә дәвам итәләр. Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссариаты, урыннардагы партия, совет оешмалары тракторларга ремонт ясау өлкәсендәге мондый җавапсыз карашлардан тиешле нәтиҗә ясарга һәм машина-трактор паркын язгы чәчүгә тулысынча һәм яхшы итеп срогында хәзерләүне кичекмәстән тәэмин итәргә бурычлылар.

Чәчү орлыкларын туплау урыннардагы эчке мөмкинлекләрдән файдалану, колхозара социалистик ярдәм оештыру нигезендә барырга тиеш. Барлык чәчү мәйданын орлык белән тулы тәэмин итү һәрбер районның турыдан-туры җаваплы бурычы. Моны үтәүдә колхозара ярдәмләшү эшен оештыру зур роль уйный. Бу өлкәдә Теләче районының „Кызыл Ямбулат“ колхозы инициативасы гүзәл үрнәк булып тора. Орлык белән колхозара ярдәмләшү эше республикабызның һәрбер районында киң колач алырга тиеш. Моның өчен бездә бөтен мөмкинлекләр бар. Аны тик оештыра белергә генә кирәк.

Агрозоотехника чараларының бөтен комплексын куллану, колхоз, совхоз һәм МТС производствосында хезмәтне дөрес оештыру—югары иген уңышы алуда, социалистик терлекчелекне үстерүдә гаять зур роль уйный. Менә шуңа күрә дә ВКП(б) райкомнары, партиянең совхоз, колхоз һәм МТС янындагы башлангыч оешмалары, райбашкарма комитеты, МТС, совхоз, колхоз җитәкчеләре чәчүгә хәзерлеккә конкрет җитәкчелек итәргә, җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерергә, агрозоотехника чараларын тулысынча үтәүгә, хезмәтне һәрбер колхозда звенолап оештырырга тиешләр.

Кардәш өч республика арасында төзелгән социалистик ярыш договоры буенча алынган зур йөкләмәләрне үтәүгә һәм арттырып үтәүгә, ярышта беренчелекне яулап алуга ирешү, бары тик, бу политик һәм хуҗалык ягыннан әһәмиятле документны—договорны барлык колхозчыларга, колхозчы хатын-кызларга, тракторчыларга, комбайнчыларга, терлекчелек тармагында эшләүче работникларга яхшы итеп аңлатканда гына һәм йөкләмәләрне үтәү өчен барлык колхозчыларны туплаганда гына мөмкин.

Партия, совет, комсомол оешмалары, җир органнары, МТС, совхоз һәм колхоз җитәкчеләре алдында торган төп бурыч: автономияле өч республика арасында 1940 нчы ел өчен төзелгән социалистик ярыш договорын киң рәвештә аңлатуны оештырудан, һәрбер колхозның, бригаданың, звеноның социалистик ярышка кушылуын тәэмин итүдән, ярыш договорларының үтәлешен системалы рәвештә тикшереп барудан гыйбарәт.

Өч республика арасында төзелгән социалистик ярыш договоры—1940 нчы елда авыл хуҗалыгының барлык тармакларында зур уңышларга ирешү өчен конкрет эш планы ул. Аны тулысынча үтәү өчен көрәшү—һәрбер партияле һәм партиясез большевикның изге бурычы.

Социалистик ярыш договоры буенча алынган йөкләмәләрне тулысына үтәү өчен большевикларча көрәшик, өч республика ярышында алдынгылыкны яулап алыйк!

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

28 нче февральдә Карелия бугазында безнең частьләрнең һөҗүме киңәюдә дәвам итте. Дошман, каршы атакалар ясап, безнең һөҗүмне туктатырга омтылып һәм зур югалтуларга дучар булып, чигенүендә дәвам итте. Безнең частьләр, **Салмен-Кайта** елгасының төньяк ярындагы оборона пунктларын алып, **Вуокси-Ярви** күленең көнбатыш ягы буенда **Рита-Саари** местечкосын, аннары **Юряпян-Ярви** күленнән төньяктарак **Мяльккеля**, **Хаммарниэми** һәм **Хейкурила** местечколарын, **Хейнь-Оки** станциясеннән 4 километр көньяк-көнбатыштарак **Кямяря** местечкосын һәм **Выборгдан** 6 километр көньяктарак **Аля-Сомме** местечкосын алдылар.

Тулы булмаган саннарга караганда, безнең частьләр 28 нче февральдә дошманның 42 ныгытылган оборона пунктын алганнар.

Фронтның башка участкыларында әһәмиятле үзгәрешләр булмады.

Һава начар булганлыктан безнең авиациянең хәрәкәтләре разведка очышлары белән генә чикләнде.

ВКП(б) ның КАЗАН ШӘҺӘР ОЕШМАСЫНЫҢ V нче КОНФЕРЕНЦИЯСЕ ДЕЛЕГАТЛАРЫ ИГТИБАРЫНА

Партиянең шәһәр күләмендәге V нче конференциясе шушы елның 3 нче мартында, 18 сәгатьтә Менжинский исемендәге клуб бинасында ачыла.

Делегатлык билетлары һәр көнне иртән 9 сәгаттән 15 сәгатькә кадәр һәм 17 сәгаттән 21 сәгатькә кадәр ВКП(б) ның Шәһәр Комитеты бинасында 19 нчы бүлмәдә бирелә. (Астрономический урам, 15/19).

Оештыру комиссиясе.

ДОГОВОР

1940 нчы елгы авыл хуҗалыгы эшләренең дәүләт планын яхшы үтәү өчен орденлы Татарстан һәм Чувашстан АССР һәм Мордовия АССР арасында СОЦИАЛИСТИК ЯРЫШ ДОГОВОРЫ

„Иң якындагы 3—4 ел эчендә гектарыннан уртача 12—13 центнер уңыш алып, ел саен 8 миллиард пот ашлык җитештерүгә ирешү өчен, техник культуралар җитештерүне уртача 30—35 процентка арттыру өчен, сарыклар һәм дуңгызлар санын ике өлеш, мөгезле эре терлекләр санын 40 процент чамасына, атлар санын 35 процент чамасына арттыру өчен игенчелегебезнең һәм терлекчелегебезнең күтәрелүен тагын да җәелдерергә“ (И. Сталин. ВКП(б) ның XVIII нче съездында ясаган докладыннан).

Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) партиясенең XVIII нче съездының тарихи карарларын тормышка ашыру өчен, орденлы Татарстан һәм Чувашстан АССР ның һәм Мордовия АССР ның совхоз, МТС эшчеләре, колхозчылары һәм колхозчы хатын-кызлары, авыл хуҗалыгы белгечләре, Сталинчыл 3 нче бишьеллыкның өченче елында, ягни 1940 нчы елда авыл хуҗалыгы эшләре планын уңышлы үтәү өчен, Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә колхозларның, совхозларның, МТС ларның һәм авыл хуҗалыгы алдынгыларының киң рәвештә катнашулары өчен үзара социалистик ярыш договоры төзиләр һәм үз өсләренә түбәндәге йөкләмәләрне алалар:

1. Агротехника чараларының бөтен комплексын тулысынча һәм югары сыйфатлы итеп үткәрергә, стахановчылар ирешкән уңышларны производствога кертергә, машина-трактор паркыннан яхшы файдаланырга һәм шул нигездә 1940 нчы елны һәр гектардан уртача кимендә түбәндәгечә уңыш алуга ирешергә.

ҮТКӘРЕЛӘ ТОРГАН ЧАРАЛАР	Татарстан АССР да	Чувашстан АССР да	Мордовия АССР да
Барлык бөртекле культуралар буенча	13 центн.	14 центн.	12 центн.
Колхозларның орлыклык участкыларында	16 „	17 „	14 „
Люцерна һәм клевер орлыклары	2 „	2 „	2 „
Бәрәңге	110 „	125 „	125 „
Тамыр азыклар	250 „	300 „	200 „
Помидор, кыяр, кишер	150 „	200 „	150 „
Суган	120 „	—	120 „
Кәбестә	300 „	350	300 „
Фрукталар	30 „	—	30 „
Җиләкләр	20 „	—	20 „

2. Машина-трактор паркыннан файдалануда комплекслы механикалаштыруга, трактор һәм кырчылык бригадаларының эшләрен бергә бәйләп алып баруга һәм авыл хуҗалыгы эшләренең югары сыйфатына төп игтибарны бирергә, рәт аралары йомшартыла торган һәм техника культураларын эшләүне механикалаштыруга аеруча әһәмият бирергә һәм йомшак җир сөрүгә күчереп исәпләгәндә һәрбер тракторның түбәндәгечә эшләвенә ирешергә (ашлык сугудан тыш):

ҮТКӘРЕЛӘ ТОРГАН ЧАРАЛАР	Татарстан АССР да	Чувашстан АССР да	Мордовия АССР да
а) лигроин белән эшли торган ЧТЗ тракторында	2.000 га	1.500 га	2.000 га
Дизельле ЧТЗ тракторында	2.000 „	—	—
Газогенераторлы ЧТЗ тракторында	1.200 „	—	1.200 „
Газогенераторлы СТЗ—НАТИ тракторында	1.000 „	900 „	1.000 „
Карбюраторлы СТЗ—НАТИ тракторында	1.300 „	1.200 „	1.300 „
СТЗ—ХТЗ тракторында	700 „	650 „	600 „
„У—2“ тракторында	500 „	400 „	500 „
б) 25 календарь көндә урып-җыярга:			
һәрбер „Коммунар“ комбайны белән	350 га һәм кимендә 4.550 цент. ашлык сугарга.	300 га һәм 4.200 цент. ашлык сугарга.	350 га һәм 4.200 цент. ашлык сугарга.
һәрбер „Сталинец“ комбайны белән	460 га һәм кимендә 5.980 цент. ашлык сугарга.	—	—
в) 70 календарь көндә ашлык сугарга:			
МК—1100 сугу машинасы белән	1.000 тонна	1.000 тонна	800 тонна
БДО—34 һәм МО—900 сугу машиналары белән	650 тонна	650 тонна	600 тонна

3. Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү һәм трактор паркыннан рациональ файдалану нигезендә планга карата киметергә:

ҮТКӘРЕЛӘ ТОРГАН ЧАРАЛАР	Татарстан АССР да	Чувашстан АССР да	Мордовия АССР да
а) ягулыклар тотуны	3 процентка	3 проц.	3 проц.
б) эшләрнең үзенә төшү бәясен	5 процентка	5 проц.	5 проц.

4. 1940 нчы елда югары иген уңышы алу бурычын тормышка ашыру өчен минимум рәвешендә түбәндәге агротехника чараларын үткәрергә:

ҮТКӘРЕЛӘ ТОРГАН ЧАРАЛАР	Татарстан АССР да	Чувашстан АССР да	Мордовия АССР да
а) кимендә 50 сантиметр калынлыкта түбәндәге мәйданда кар тотарга	1 миллион га	185 мең га	400 мең га
б) басуга тирес чыгарырга	15 миллион йөк	6 миллион 300 мең йөк	3 миллион 900 мең йөк
Шул исәптән кышкы чорда	10 миллион 500 мең йөк	3 миллион 900 мең йөк	2 миллион 700 мең йөк
в) торф хәзерләргә	400 мең тонна	820 мең тонна	150 мең тонна
г) сабан ашлык чәчеләчәк җирләргә көл белән ашларга	35 мең тонна	6.600 тонна	6.000 тонна
д) иртә чәчелә торган башаклы һәм кузаклы культуралар чәчүне тәгәлләргә	5—7 көндә	5—6 көндә	5—7 көндә

5. Уҗым һәм бөртекле сабан-ашлык культураларын югары сыйфатлы һәм агуланган орлыклар белән чәчәргә, шул исәптән сортлы орлыклар белән:

ҮТКӘРЕЛӘ ТОРГАН ЧАРАЛАР	Татарстан АССР да	Чувашстан АССР да	Мордовия АССР да
а) сабан ашлыгын түбәндәге мәйданда	1 миллион 400 мең га	188 мең 900 га	291 мең 120 га
б) уҗымнарны түбәндәге мәйданда	910 мең га	195 мең га	258 мең га

6. Һәрбер колхозда һәм совхозда барлык культуралар буенча орлыклык участкыларда иң яхшы сортлы орлыклар чәчәргә.

7. Яровойлаштырылган орлыклар чәчәргә:

ҮТКӘРЕЛӘ ТОРГАН ЧАРАЛАР	Татарстан АССР да	Чувашстан АССР да	Мордовия АССР да
а) бөртекле культуралар	600 мең га	100 мең га	240 мең га
б) бәрәңгене	15 мең га	6 мең га	5 мең га
8. Сабан һәм уҗым ашлыкларын тезмә чәчү машиналары белән чәчәргә	Барлык мәйданны	Барлык мәйданны	Барлык мәйданны
Шул исәптән кимендә түбәндәге мәйданда шакмаклап чәчәргә	200 мең га	60 мең га	20 мең га

ҮТКӘРЕЛӘ ТОРГАН ЧАРАЛАР	Татарстан АССР да	Чувашстан АССР да	Мордовия АССР да
9. Туңга сөрелгән һәм кара пар җирләрен яз көне тырмалауны түбәндәге срокларда үткәрергә	2—3 көндә	2—3 көндә	2—3 көндә
10. Туңга сөрелгән җирләрне чәчү алдыннан культивацияләүне яки лущить итүне үткәрергә	100 %	100 %	100 %
11. Уҗым тырмалау үткәрергә:			
а) түбәндәге мәйданда	400 мең га	150 мең га	200 мең га
б) түбәндәге срокларда	3—4 көндә	3—4 көндә	3—4 көндә
12. Җәй көне бәрәңге утырту	1.000 га	500 га	1.000 га

13. 1940 нчы елда һәрбер колхозда яшелчә-бакча культураларын чәчүне кертүгә ирешергә һәм түбәндәгеләрне үтәргә:

ҮТКӘРЕЛӘ ТОРГАН ЧАРАЛАР	Татарстан АССР да	Чувашстан АССР да	Мордовия АССР да
а) хөкүмәт тарафыннан билгеләнгән парник-теплица хуҗалыгы планын	100 %	100 %	100 %
б) шәһәр тирәсендәге яшелчәчелек зонасына керә торган районнарда бәрәңгене һәм яшелчәне түбәндәге мәйданда чәчәргә	38.500 га	11.735 га	9.500 га
14. Җимеш һәм җиләк бакчалары утырту:			
а) җимеш бакчаларын	900 га	—	800 га
б) җиләклекләр	250 га	550 га	50 га
в) колхозларда җиләк-җимеш питомниклары булдырырга	100 га	35 га	10 га
15. 1940 нчы елда кырларны корылыктан саклау өчен урман полосалары булдырырга һәм чокыр кырыйларына агачлар утыртырга	3.100 га	—	1.900 га
16. Сабан һәм уҗым культураларын тукландырырга	50.000 га	80.000 га	1.700 га
17. Чәчүлекләрне сугару	2.500 га	400 га	1000 га
18. Бөртекле культураларны кимендә ике тапкыр утауны һәм киң рәтле чәчүлекләрнең араларын йомшартуны үз вакытында үткәрергә	100 %	100 %	100 %
19. Бөртекле культураларның барлык орлык участкыларында сортлы утау үткәрергә	100 %	100 %	100 %
20. Көзге һәм язгы бодайны сорт эчендә серкәләндерүне кимендә түбәндәге сандагы колхозларда үткәрергә	1000 колхозда	100 колхозда	500 колхозда
21. Барлык мәйданда пар сөрүне түбәндәге срокта тәгәлләргә	1 июнь	1 июнь	1 июнь
22. Ремонтны югары сыйфатлы итеп тәгәлләргә:			
а) тракторларны	25 фев-дә	1 апрельдә	1 мартта
б) печән чабып-җыю машиналарын	15 майда	20 майда	15 майда
в) комбайннарны, ашлык сугу машиналарын, орлык чистарту һәм урып-җыю машиналарын, инвентарьларны	15 июньдә	20 июньдә	15 июньдә
23. Печән чабып-җыюны югары сыйфатлы итеп игеннәрне урып-җыю башланганга кадәр тулысынча тәгәлләргә	5 көн элек	5 көн элек	5 көн элек

24. Игеннәрне урып-җыю башланганга кадәр түбәндәгеләрне төзәргә:

а) барлык колхозларда ашлык киптерү урыннарын.

б) комбайннардан алынган ашлыкларны бушату һәм киптерү өчен барлык колхозларда лапаслар.

в) барлык бригадаларда ябык ындыр табаклары.

25. Барлык колхозлардагы һәм совхозлардагы ындыр табакларын, амбарларны, тараны, транспорт инвентарьларын, урып-җыю һәм ашлык сугу машиналарын, шулай ук Заготзерноның һәм Госсортфондның техник базасын кичекмәстән хәзерләргә һәм аларга дезинфекция ясарга . . . . 10 июльгә 10 июльгә 10 июльгә

26. Лобогрейкалар һәм жаткалар белән урып-җыюның түбәндәге срокларын билгеләргә:

ҮТКӘРЕЛӘ ТОРГАН ЧАРАЛАР	Татарстан АССР да	Чувашстан АССР да	Мордовия АССР да
а) уҗым ашлыкларын	5—6 көндә	5—6 көндә	5—6 көндә
б) башаклы сабан ашлыкларны	7—8 „	8—10 „	7—8 „
в) кузаклы культураларны	6—7 „	8—10 „	6—7 „

27. Урылган барлык игеннәрне көлтәгә бәйләргә, үз вакытында чүмәләләргә куярга, уру белән көлтә бәйләү арасында өзеклеккә юл куймаска.

ҮТКӘРЕЛӘ ТОРГАН ЧАРАЛАР	Татарстан АССР да	Чувашстан АССР да	Мордовия АССР да
28. Барлык урылган ашлыкларны түбәндәге сроклардан кичекмичә скерткә куярга	10—15 көннән	10—15 көннән	10—15 көннән
29. Ашлык сугуны урып-җыю башлануның 3—5 нче көнендә башларга һәм түбәндәге сроктан кичекми тәгәлләргә	15 октябрьдә	1 октябрьдә	15 октябрьдә

30. Барлык урып-җыю машиналарына орлык тоткычлар куярга. Урып-җыйган басуларда башакларны атлы һәм кул тырмалары белән тоташтан җыюны вактында үткәрергә. Көлтә ташу өчен билгеләнгән барлык арбаларны, фургоннарны, колымагаларны, рыйдваннарны торыпшалар, кабыклар, такталар һәм башкалар белән ябуларга.

31. Бригадаларда һәм звеноларда иген уңышын дөрес учетка алырга.

32. 1940 нчы елда техника культураларының һәрбер гектарыннан уртача кимендә түбәндәге уңышны алуга ирешергә:

ҮТКӘРЕЛӘ ТОРГАН ЧАРАЛАР	Татарстан АССР да	Чувашстан АССР да	Мордовия АССР да
а) җитен сүсе	3,5 цент.	3,5 цент.	—
б) киндер сүсе	4,5 „	5,0 „	5 цент.

(Ахры 2 нче биттә).

СОЦИАЛИСТИК ЯРЫШ ДОГОВОРЫНЫҢ ДӘВАМЫ

ҮТКӘРЕЛӘ ТОРГАН ЧАРАЛАР	Татарстан АССР да	Чувашстан АССР да	Мордовия АССР да
в) кук сагыз тамырлары (чи килеш)	20 центнер	— центнер	— центнер
г) көнбагыш	8 „	—	8 „
д) махорка	—	20 „	—
33. 1940 нчы елда югары иген уңышы алу бурычын тормышка ашыру өчен, минимум рәвешендә, түбәндәге агротехника чараларын үткәрергә:			
а) техника культураларын чәчүне тәгәлләргә	5—7 көндә	5—6 көндә	5—7 көндә
б) техника культураларының орлыклык участкыларына иң яхшы сортлы орлыклар чәчәргә.			
в) техника культураларын кимендә 2 тапкыр утауны һәм киң рәтле чәчүлекләрнең рәт араларын үз вактында йомшартуны үткәрергә	100%	100%	100%
г) техника культураларының орлыклык участкыларында сортлы утау үткәрергә	100%	100%	100%
34. Каучуклы куксагыздан югары һәм ныклы уңыш алу өчен түбәндәге чараларны үткәрергә:			
а) куксагызны иң яхшы һәм югары уңдырышлы җирләргә чәчәргә	100%	100%	—
б) пар сөрү чорында һәм чәчү алдыннан туфракны эшләгәндә түбәндәге күләмдә ашламалар кертергә:			
тирес (һәрбер гектарга 40—50 тонна исәбеннән)	160 мең тонна	2 миллион 400 мең йөк	—
минераль ашламалар	1.500 тонна	820 тонна	—
35. Техника культураларын җыюны түбәндәге срокларда тәгәлләргә:			
а) көнбагышны	10 көндә	—	10 көндә
б) җитен йолкуны	8 „	4—5 көндә	8 „
в) киндер басасын алуны	10 „	4—5 „	10 „
г) җитен җәюне һәм чылатуны тәгәлләргә	1 сентябрьгә	—	1 сентябрьгә
д) киндер чылатуны тәгәлләргә	10 октябрьгә	15 октябрьгә	10 октябрьгә
е) куксагыз тамырларын йолкуны, киптерүне һәм тапшыруны түбәндәге срокка тәгәлләргә	1 ноябрьгә кадәр	—	—
36. Бөртекле культураларны урып-җыйганнан соң камыл лущить итүне үткәрергә	100 мең га	35 мең га	75 мең га
37. Көзге чәчүне югары сыйфатлы итеп иң яхшы агротехник срокларда үткәрергә, аны түбәндәге сроктан да кичекмичә тәгәлләргә	25 августка	25 августка	25 августка
38. Дәүләт каршындагы йөкләмәләрне: ашлык тапшыруны, орлык ссудаларын кайтаруны, натуралата түләүне, техника культураларын, яшелчәләрне контрактация договорлары буенча тапшыруны һәм бәрәңге тапшыруны срогыннан элек үтәргә.			
39. 1941 нче елда югары уңыш алу өчен көрәш теләге белән туңга сөрү үткәрергә:			
а) түбәндәге мәйданда	1 миллион 725 мең га	270 мең га	580 мең га
б) түбәндәге срокларда	1 октябрьгә	1 октябрьгә	1 октябрьгә
в) шул ук срокка кара пар сөрергә	200 мең га	30 мең га	100 мең га
40. Һәрбер трактор бригадасында, шулай ук колхоз һәм совхоз кыр станнарында культуралы-җиһазландырылган кимендә берәр вагон булдырырга, аларны музыка инструментлары, шашкалар, шахматлар, газеталар, журналлар, китапханәләр һәм аптечкалар белән тәэмин итәргә.			
41. Авыл хуҗалыгы эшләре чорында колхозчыларга, тракторчыларга, комбайнчыларга кирәкле әйберләрне һәм продуктларны турыдан-туры басуда сату өчен күчмә ларекләр булдырырга, шулай ук җәмәгать туклануы оештырырга.			
42. Басуда агитация-масса эшен үткәрү өчен, һәрбер районда күчмә кинолы, радиолы һәм үзешчәнлек түгәрәкләре булган агитбригадалар оештырырга.			
43. Кыр эшләре вактында һәрбер колхозда, совхозда балалар ясләләре, балалар площадкалары, балалар бакчалары оештырырга, аларны хәзерлекле җитәкчеләр белән, культура-көнкүреш инвентарьлары һәм тукландыру белән тәэмин итәргә.			
44. Колхозларда җәмәгатьләштерелгән терлекчелекне үстерү буенча дәүләт планын, ВКП(б) Үзәк Комитетының һәм СССР Совнаркомының 1939 нчы ел 8 нче июль карарына тулысынча туры китереп үтәргә һәм 1940 нчы елны совхозларда терлекләр санын арттыру планын үтәргә.			
45. Һәрбер колхозда өчәртерлекчелек фермасы оештыруга ирешергә, терлекләр санын, кимендә, билгеләнгән күләмгә җиткерергә	колхозларның 35% ында	колхозларның 25% ында	колхозларның 30% ында
46. Колхозларның товарлыклы фермаларында терлекләрне түбәндәге санга җиткерергә:			
а) товарлыклы сөтчелек фермаларында	205 мең башка	55 мең башка	62 мең башка
б) товарлыклы дуңгыз фермаларында	192 мең башка	66 мең башка	84 мең башка
в) товарлыклы сарык фермаларында	510 мең башка	56 мең башка	145 мең башка
г) товарлыклы ат фермаларында	23 мең башка	2 мең башка	13 мең 500 башка
д) йорт куяннары фермаларындагы ана куяннар	32 мең башка	2 мең башка	1 мең 700 башка
е) кош фермаларында	72 мең башка	34 мең башка	28 мең башка
ж) җәнлек фермаларында	1 мең 900 башка	25 башка	—
47. Колхозларда атларның гомуми санын түбәндәге санга җиткерергә	370 мең башка	128 мең башка	102 мең башка
48. Умарта семьяләре санын	247 мең башка	52 мең башка	57 мең башка
49. Елына уртача түбәндәгеләрне алуга ирешергә:			
а) һәрбер фуражный сыердан сөт савып алырга (кимендә)	1.300 литр	1.200 литр	2.000 литр *)
б) 6 айга кадәр бозауның тәүлегенә уртача үсеш бирүенә	450 грамм	450 грамм	450 грамм
в) һәрбер сарыктан йон алырга:			
нечкә йонлы сарыктан	4,5 кг.	—	4,5 кг.
ярым тупас йонлы сарыктан (метислардан)	2,5 „	2,5 кг.	2,5 „
тупас йонлы сарыктан	2,0 „	—	2,0 „
50. Ана терлектән алырга һәм үстерергә:			
һәрбер 100 сыердан кимендә	90 бозау	90 бозау	90 бозау
һәрбер 100 сарыктан кимендә	130 бәрән	105 бәрән	130 бәрән
һәрбер 100 биядән кимендә	70 тай	60 тай	70 тай
һәрбер ана дуңгыздан кимендә	12 дуңгыз баласы	13 дуңгыз баласы	18 дуңгыз баласы
һәрбер ана куяннан кимендә	20 куян баласы	—	—
51. Терлекләрнең нәселен яхшырту теләге белән метислаштыру үткәрергә:			
а) мөгезле эре терлекләр	93 мең баш	32 мең баш	25 мең баш
б) бияләр	54 мең 100 баш	20 мең баш	28 мең 600 баш
в) сарыклар	280 мең баш	24 мең баш	85 мең баш
г) дуңгызлар	22 мең баш	16 мең баш	31 мең баш
52. Иң яхшы үрчеткечләр белән ясалма рәвештә орлыкландырырга:			
а) бияләрне	13 мең баш	3 мең баш	4 мең 500 баш
б) сыерларны	40 мең баш	16 мең баш	10 мең баш
в) сарыкларны	300 мең баш	60 мең баш	80 мең баш
53. Колхозларда терлек азыгы базаларын яхшырту буенча түбәндәге чараларны үткәрергә:			
а) силос салырга (кимендә)	600 мең тонна	100 мең тонна	75 мең тонна
б) шулардан: һәрбер колхоз силос салу планын түбәндәге срокларга үтәргә тиеш:			
а) 20 нче июльгә	80%	80%	80%
1 нче октябрьгә	100%	100%	100%
в) печән чабу	312 мең га	60 мең га	110 мең га
г) ясалма болыннар һәм көтүлек җирләре булдырырга	5.000 „	1.500 „	1.000 „
д) болыннар булдыру өчен җир сөрергә (кимендә)	7.000 „	3.000 „	1.200 „
е) куаклыкларны чистартырга	1.000 „	1.200 „	400 „
ж) болыннарны һәм көтүлек җирләрен чистартырга	5.000 „	300 „	1.200 „
з) болыннарны һәм көтүлек җирләрен киптерергә	500 „	800 „	500 „
54. Терлекчелек корылмалары төзү планын тулысынча үтәргә	1 октябрьгә	1 октябрьгә	1 октябрьгә
55. Барлык терлекчелек корылмаларына елына кимендә ике тапкыр җентекләп дезинфекция үткәрергә, шулардан:			
а) беренче тапкыр	15 майга	15 майга	15 майга
в) икенче тапкыр	1 октябрьгә	1 октябрьгә	1 октябрьгә
56. Колхозларда һәм совхозларда терлекчелек буенча ветеринария-профилактика һәм зоотехника чараларын тулысынча үткәрүне тәэмин итәргә.			
57. 1940 нчы елны мәктәпләр һәм төрле курслар аркылы кадрлар хәзерләргә һәм яңадан хәзерләргә:			
а) МТС механиклары (кимендә)	100 кеше	60 кеше	60 кеше
б) трактор отрядлары бригадирлары (кимендә)	200 „	110 „	250 „
в) комбайнчылар (кимендә)	1.400 „	180 „	300 „
г) барлык маркадагы тракторлар өчен тракторчылар	6.800 „	950 „	3.735 „
д) шоферлар (кимендә)	400 „	—	90 „
е) производстводан аермыйча хатын-кызлардан тракторчылар хәзерләргә (кимендә)	2.000 „	500 „	1.000 „
ж) кырчылык бригадалары бригадирлары	2.170 „	390 „	700 „
з) колхоз хисапчылары	1.200 „	660 „	600 „
и) яшелчәчеләр	550 „	—	175 „
к) агротехниклар	100 „	—	80 „
л) ветфельдшерлар	900 „	420 „	315 „
м) терлекчелек фермалары мөдирләре	1.100 „	—	500 „
н) ат фермалары мөдирләре	300 „	—	300 „
о) умартачылар	700 „	—	315 „
п) ясалма орлыкландыру буенча техниклар	1.700 „	—	170 „
р) колхозчыларның массовый күләмдә агротехника укуларын оештыру белән бергә колхозларда оештырырга (кимендә)	стахановчылар өчен 1.000 мәктәп	500 мәктәп һәм агро-түгәрәкләр	стахановчылар өчен 500 агро-түгәрәк

Колхозларда даими производство бригадаларын барлык чаралар белән ныгытырга һәм барлык колхозларда һәм бригадаларда хезмәтне звенолап оештыруга күчәргә, шуның белән стахановчылык хәрәкәтенең үсүе өчен, хезмәтнең житештерүчәнлеген күтәрү өчен шартлар тудырырга. Җир органнары, авыл хуҗалыгы белгечләре, колхозларның һәм совхозларның җитәкчеләре стахановчылык хәрәкәтен киң күләмдә оештырырга һәм аңа җитәкчелек итәргә, авыл хуҗалыгы алдынгыларының Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә күрсәтелгән бай тәҗрибәсеннән файдаланып йөзпотчылар бригадаларының һәм стахановчы звеноларының эшенә көн саен практик ярдәм күрсәтергә тиешләр.

Бу социалистик ярыш договорының үтәлешен өч тапкыр тикшерергә: беренче тапкыр—язгы чәчү тәмам булганнан соң, икенче тапкыр—урып-җыю алдыннан һәм өченче тапкыр—ноябрь аенда.

„Правда", „Социалистическое земледелие" һәм „Животноводство" газеталарының редакцияләреннән ярышның арбитры булуны үтенергә.

*) Мордовия АССР буенча күрсәткеч һәрбер савым сыердан.

ТАТАРСТАН АССР дан | ЧУВАШСТАН АССР дан | МОРДОВИЯ АССР дан



Чит илләрдә

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 28 февраль. Кичә кич рәсми рәвештә хәбәр ителүгә караганда, Франция эсминецы Финистерре мысы янында (Испаниянең төньягында) немецләрнең су асты көймәсен батырган.

Бүген иртәнге белдерүдә фронтның төрле участкыларында патрульләрнең хәрәкәте һәм артиллериядән аз гына атыш булганлыгы әйтелә.

БЕРЛИН, 28 февраль. Германия армиясенең верховный командованиесе сводкасында болай диелә: „Мозельдән көнчыгыштарак, Перля районында бүген төнлә дошманның зур удар отрядының артиллерия ярдәме белән булган атакасы уңышлы рәвештә кире кагылды. Германия авиациясе 27 нче февральгә каршы төндә Франция өстендә озак очышлар ясады. Германия самолетларының күбесе Париж өстендә очтылар.

Германия авиациясенең Төньяк диңгез, Англия һәм бер кадәр Франция өстендә ясаган һава разведкасы күп кенә урыннарда дошман оборонасының көчле утына очрады. Германиянең Англиягә разведкага киткән 2 самолеты үз базаларына кайтмадылар. Без Англиянең бер разведка самолетын бәреп төшердек".

ЛОНДОН, 28 февраль. Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Норвегиянең „Арнфинн" пароходы су асты көймәсенә бәрелгән. Көймә тишелеп баткан булса кирәк. Пароход агым белән Норвегия ярлары янына агып киткән. Команда коткарылган.

Англиянең сугыш карабы Швециянең Норвегия янында баткан „Нордиа" пароходының 17 пассажирын Шотландиягә төшерде. Пассажирларның 2 се үлгән.

Төньяк диңгездә Англиянең „Эфос" пароходы баткан. Команда составының 19 кешесен Голландия пароходы Англиягә китергән. Экипажның калган членнары да коткарылганнардыр дип уйлыйлар.

ТҮБӘНГЕ ПАЛАТАДА ЧЕРЧИЛЛЬ РЕЧЕ

ЛОНДОН, 28 февраль. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, диңгез эшләре министре Черчилль кичә түбәнге палатада диңгез флотына акча бирү турында такдим ясап речь сөйләгән.

Черчилльнең белдерүенчә, әлегә кадәр сугышның төп авырлыгы диңгез флотына йөкләтелгән. Киләчәктә „Англиянең диңгез көчләренә хәзерге вакыттагыга караганда киңрәк күләмдә атакалар ясалачак, ә Англиянең яшәве флотка бәйләнгән".

Төрле сәбәпләр нәтиҗәсендә Германиянең су асты флотында зур югалтулар булганлыкны күрсәтеп, Черчилль шул ук вакытта „хәзер Германиянең операцияләр алып бара торган аз санлы су асты көймәләреннән дә Англиянең шактый югалтулар ясаганлыгын" икрар итте. Җәй житү белән Германиядә су асты көймәләренең саны шактый артачак һәм Англия „аларны су асты көймәләренә каршы көрәшү өчен махсус рәвештә төзелгән яңа караблар белән каршы алырга тиеш".

Мина атакаларына каршы көрәшү өчен Англия хөкүмәте, Черчилльнең белдерүенә караганда, балык тоту флотыннан һәм балыкчылардан файдалана. Хөкүмәт шулай ук сәүдә һәм балык тоту флотын да кораллandырырга карар биргән.

Черчилль нейтраль илләрнең позициясен нык тәнкыйть итте. Ул аларны, „Германия яклый торган доктринага ияреләр" дип гаепләде.

Нейтраль илләрнең бу позициясенә кагылып, Черчилль болай диде: „Боларның барсының да Англия хөкүмәтен туйдырып бетергәнлеге гаҗәп түгел. Алар минем үземне дә туйдырып бетерделәр". Шул уңай белән Черчилль киләчәктә Англия хөкүмәте нейтраль илләргә кагыла торган кагыйдәләрне һәм конвенцияләрне „формаль төстә аңлату"дан баш тартырга тиеш диган мәсьәләне кискен итеп куйды.

Диңгез сугышының 6 айлык йомгакларына кагылып, Черчилль, Англия сугыш флоты югалтуларының гомуми тоннажы 63 мең тонна, ә сәүдә флотының „саф югалтулары" 200 мең тонна икәнлекне күрсәтте. Черчилль, Англиянең „Бархэм" линкорының торпедадан зарарланганлыгын һәм „Нельсон" диган икенче бер линкорның үткән елның декабрендә магнитлы минага бәрелгәнлеген икрар итте. Черчилльнең сүзләренә караганда, бу линкорлар икесе дә тиз арада сафка басачаклар. Аннары ул, Англиянең хәзерге барлык линкорларының үткән сугыштан калган иске линкорлар икәнлеген һәм якын арада диңгез флотына „Король Георг V нче" классындагы 5 яңа линкор өстәләчәкне күрсәтте.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

Гуанси провинциясенең көньяк өлешендә Наньниннан төньяктарак сугышлар бара. Хәбәр итүләренә караганда, шәһәр японнар кулында. Наньнин—Биньян шоссесендә, Саньтан районында япон гаскәрләре, югалтулардан соң үз частьләрен көчәйтеп, кытай позицияләренә яңадан атака ясадылар, ләкин кире кагылдылар.

ҮЗӘК КЫТАЙДА

Чжецзян провинциясенең төньяк өлешендә, Сяошань районында — тынлык. Японнар командованиесе монда көн саен яңадан-яңа гаскәрләр җибәреп тора. Якын көннәрдә монда японнар зур һөҗүм башларлар дип уйлыйлар.

Цзянси провинциясендә, Наньчаннан көньяк-көнбатыштарак кытай гаскәрләре японнарның Гаоюшидәге позицияләренә уңышлы һөҗүм ясадылар. Японнар ягыннан үлгән һәм яраланган кешеләр 200 ләп санала. Кытайлар японнарның 100 мылтыкларын кулга төшергәннәр.

Аньхуэй провинциясенең көньяк-көнчыгыш өлешендә кытай гаскәрләре Фаньчан секторында уңышлы һөҗүм алып баралар.

Хэнань провинциясенең көньяк өлешендә кытай частьләре Синьян секторында японнарның тышкы оборона линиясенә атака ясадылар.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА

Суйюань провинциясенең көнбатыш өлешендә кытай гаскәрләре Уюань тирәсен чолгап алуны дәвам иттерәләр. Кытайларның алгы частьләре шәһәргә якынайдылар һәм аның бистәләрендә сугыш алып баралар. Шушы көннәрдә генә Уюаньнан көньяктарак һәм төньяктарак каты сугышлар булган. Кытай частьләренең берсе, Уюань—Баотоу шоссесе буйлап хәрәкәт итеп, 21 нче февральдә Уюаньнан 75 километр көньяк-көнчыгыштарак Улашухайга атака ясаган.

Сайтоны Япония парламентыннан чыгару турындагы мәсьәлә тирәсендә көрәш

ТОКИО, 28 февраль. (ТАСС). „Асахи" газетасының язуына караганда, хөкүмәтнең сугыш даирәләре Сайтоны парламент членлыгыннан чыгаруны яклыйлар (мәгълүм ки, Сайто түбәндәге палатада кытай мәсьәләсендә Япония хөкүмәтенең һәм сугыш даирәләренең юлын нык тәнкыйть итеп чыккан иде). Газетаның язуына караганда, хөкүмәт Сайто речен „хыянәтче рече, һәм шунлыктан Сайтоны җәзалау турындагы мәсьәләдә бернинди икеләнү булырга мөмкин түгел" дип саный. „Хөкүмәт бу мәсьәләдә түбәнге палатаның хәрәкәте ничек булачакны игтибар белән күзәтә".

24 нче февральдә дисциплинар комитетта Сайто аңлату биргәннән соң Сайтоны парламенттан чыгаруны яклаучылар белән моңа каршы чыгучылар арасында каршылыклар көчәйгән. Бу каршылыклар Минсейто, Сейюкай, Сякай Тайсюто партияләре сафларында каугa китереп чыгарган.

Аннары газетаның язуына караганда, Сайтоның түбәнге палатада сөйләгән реченең стенографиясе тулы фикер туплый алсыннар өчен парламент членнарына өләшенәчәк.

„Йомиури" газетасының язуына караганда, дисциплинар комитетның барлык членнары Сайтоны парламенттан чыгару дөрес булмас дигән нәтиҗәгә килгәннәр. Түбәнге палата депутатлары арасында Сайтога симпатия көннән-көн үсә. Газета, Сайтоның эше—парламентта кайчан булса да тикшерелгән иң кыен мәсьәләләрнең берсе дип яза.

„Мияко" газетасы үзенең баш мәкаләсендә, сугыш вакты шартларында Сайто эше „зур проблема булып әверелә һәм халыкка зур йогынты ясавы мөмкин" дип яза.

ПАРТИЯНЕҢ РАЙОН КОНФЕРЕНЦИЯЛӘРЕНДӘ

БАУМАН РАЙОНЫНДА

Райком секретареның отчеты буенча фикер алышулар зур активлык белән барды. Сөйләргә теләгән 58 делегаттан 30 иптәш чыгып сөйләде.

Конференциянең 28 нче февральдәге кичке утырышында ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Гафиятуллин речь белән чыкты. Ул үзенең чыгышында наркоматлар янындагы партоешмаларның үз эшләрен XVIII нче съезд карарлары нигезендә үзгәртеп коруны бик акырын алып баруларын, район күләмендә партия пропагандасының торышы әле һаман да канәгатьләнерлек булмавын күрсәтеп үтте. Иптәш Гафиятуллин чыгышыннан соң конференция делегатларының тәкъдиме буенча фикер алышулар туктатылды. **Конференция райкомның эшен канәгатьләнерлек дип тапты.**

29 нчы февральдә иртәнге утырышта райком пленумы составына членлыкка һәм кандидатлыкка, шулай ук партиянең шәһәр конференциясенә делегатлыкка кандидатуралар күрсәтү һәм аларны тикшерү барды. Райком пленумына член итеп 37 кеше, кандидат итеп 9 кеше, ВКП(б) ның Казан шәһәр конференциясенә тавыш бирү хокукы белән 101 делегат, киңәш бирү хокукы белән 24 делегат сайланырга тиеш.

М. Ш.

СТАЛИН РАЙОНЫНДА

ВКП(б) сафларына яңа кабул ителгән иптәшләрне большевистик тәрбияләү партия оешмаларының иң әһәмиятле бурычларыннан берсе. Ләкин партиянең Сталин райкомы бу мәсьәләгә җидди игтибар итмәгән. Район конференциясенең барышында бу нәрсә бигрәк тә ачык күренде. Партиянең район оешмасында кандидатлык стажлары үткән 296 кеше хисаплана. Менә бу сан үзе генә дә яшь коммунистлар арасында эшләүнең һич тә канәгатьләнмәслек баруын ачык күрсәтә.

— Партиягә яңа кабул ителгәннәр белән,—ди иптәш Зайцев („Светоч" фабрикасы),—райком бер җыелыш та үткәргәне юк. Райком работниклары башлангыч оешмаларда кандидатлар белән эшләүнең торышын ачык белмиләр. Безнең оешмада гына да 32 кандидат бар. Ә аларны тәрбияләү буенча системалы эш алып барылмый.

Делегатлардан шундый ук фактларны тагын Кузьмин (Мехкомбинат), Крылова (тимер юл мәктәбе) һәм башка иптәшләр күрсәтеп үттеләр. Бу турыда конференциянең карарында да нык күрсәтелде.

Конференция ВКП(б) райкомының политик линиясен дөрес һәм практик эшен канәгатьләнерлек дип тапты.

Ахметов.

МОЛОТОВ РАЙОНЫНДА

Кичә иртәнге утырышта фикер алышулар тәмам булды. Отчет-доклады буенча барлыгы 33 кеше сөйләде. Фикер алышулар зур активлык белән барды һәм райкомның эш практикасында булган кимчелекләрне бик урынлы һәм дөрес тәнкыйтьләделәр. Моны райком секретаре иптәш Палагин үзенең йомгаклау речендә тулысынча таныды. Ләкин, иптәш Палагин кайбер иптәшләрнең тәнкыйтьләре белән, аеруча, райкомның җитәкчелегенә карата булган кискен тәнкыйть белән ничектер килешмәде. Ул үзен төрле юллар белән аклау юлына басты. Кирпеч комбинаты мәсьәләсендә бу тагын да ачыграк күренде. Комбинатның партия һәм хуҗалык оешмаларына райкомның җитәкчелеге һич канәгатьләнерлек түгел. Комбинатта эшнең торышы начар. Шуңа карамастан, иптәш Палагин, „мин анда үзем булдым, киңәшмәләр, җыелышлар үткәрдем" дип акланырга маташты. Ләкин практик эшне яхшыртуга бер төрле йогынты ясамаган җыелышлардан нинди файда бар соң?

Конференция район партия оешмасының эшендәге политик юлны дөрес һәм практик эшне канәгатьләнерлек дип тапты һәм ВКП(б) ның тарихи XVIII нче съезды карарларын тормышка тулысынча ашыру өчен конкрет чаралар билгеләп карар кабул итте.

Кичке утырышта конференция үз эшенең иң җаваплы чорына—райком һәм ревизия комиссиясе составларына, Казан шәһәр партия оешмасының V нче конференциясенә делегатлыкка кандидатуралар күрсәтү һәм кандидатураларны тикшерү эшенә керешә. Кандидатураларны тикшерү эше гаять зур оешканлык һәм күтәренкелек белән үтте.

Р. Баһау.

КИРОВ РАЙОНЫНДА

27 нче февральдә булган кичке утырышта фикер алышулар тәмамланганнан соң, конференция райкомның эше турында резолюция кабул итте. Делегатлар райкомның политик линиясен дөрес, практик эшен канәгатьләнерлек дип таптылар.

28 нче февральдә булган кичке утырышта мандат комиссиясенең доклады тыңланды. Аннары, конференция ябык (яшерен) тавышка кую тәртибендә райком пленумы составына член итеп 45, кандидат итеп 9 кеше сайлады. Райкомның ревкомиссиясе составына 5 кеше сайланды. Партиянең Казан шәһәр конференциясенә тавыш бирү хокукы белән 66, киңәш бирү хокукы белән 23 делегат сайланды.

Шуның белән конференция үзенең эшен тәмамлады. Конференция идея-политик яктан гаять югары дәрәҗәдә үтте.

Ишкаев.

Партиянең Бауман районы конференциясендә катнашучы делегатлардан бер төркем. (Сулдан)—Татар совет классик язучысы Шәриф Камал (Байгельдиев), Юридик институтның кафедра җитәкчеләре—А. П. Владимиров һәм А. И. Левшин, КАИ директоры И. С. Шухов иптәшләр. М. Солтанов фотосы.

ҖЫЕЛЫШ БОЛЬШЕВИСТИК ТӘНКЫЙТЬ АСТЫНДА ҮТТЕ

(Үз хәбәрчебездән телефон буенча)

26 һәм 27 нче февральдә Чепья районы коммунистларының район җыелышында ВКП(б) райкомының эше турында отчет доклады буенча фикер алышулар булды. Фикер алышуларда 28 кеше катнашты. Чыгып сөйләүче иптәшләр райкомның эшен каты тәнкыйть уты астына алдылар. Иптәш Вафин язгы чәчүгә хәзерлек эшендә булган җидди кимчелекләр турында сөйләде. Райкомда булган саннарга караганда, 6 мең центнерга якын чәчүлек орлыгы җитми. Ләкин районның кайбер колхозларында чәчүлек орлыгы артып кала. Бу эш буенча колхозара ярдәм җитәрлек оештырылмаган. „Правда" колхозы җитәкчеләре чәчүлек орлык җитмәү турында сөйлиләр, ә фактта исә бу колхозда чәчүлек орлык артып та кала. Мондый фактлар районның башка колхозларында да бар.

ВКП(б) райкомының инструкторлары колхозлардагы башлангыч партоешмаларга җитәрлек практик ярдәм күрсәтмиләр, мисальгә Дмитров исемендәге МТС партоешмасын алырга була. Бу МТС республикабызда иң начар эшләүче МТС ларның берсе. Ул, 1939 нчы елның тракторлар эше планын бары тик 54 процент итеп үтәде. Тракторларны һәм авыл хуҗалыгы машиналарын ремонтлау эше хәзер дә гафу ителмәслек начар тора. Ә райком инструкторлары бу МТС ка җитәрлек игтибар бирмиләр.

Райком пропагандисты иптәш Николаев партия пропагандасы эшендә булган зур кимчелекләргә тукталды. Райком секретарьлары партия тарихын өйрәнү турында җыелышларда күп сөйлиләр һәм аерым иптәшләрне тәнкыйть итәләр. Ләкин бу мәсьәләдә үзләре башкаларга үрнәк була алмыйлар әле.

Районда чыга торган „Коммунар", „Әзляни" газеталары „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н үзлекләреннән һәм түгәрәккә йөреп өйрәнүче иптәшләрнең тәҗрибәләрен җитәрлек яктыртмыйлар.

Конференция райкомның эшен канәгатьләнерлек дип тапты.

28 нче февральдә сайлаулар булды. Ябык (яшерен) тавышка кую тәртибендә ВКП(б) райкомы пленумы составына 21 член, 5 кандидат һәм ревизия комиссиясенә 5 кеше сайланды. ВКП(б) ның Татарстан өлкә конференциясенә тавыш бирү хокукы белән Фәйзуллин, Әхметшин һәм киңәш бирү хокукы белән Вафин иптәшләр сайландылар. Шул ук көнне ВКП(б) райкомы пленумының беренче утырышы булды. Пленум 7 кеше составында бюро сайлады. Райкомның беренче секретаре итеп иптәш Фәйзуллин, икенче секретарь итеп Әхметшин, өченче секретарь итеп Самсонова иптәшләр сайландылар.

Х. Галләмов.

КУЗНЕЧИХА РАЙОНЫНДА

Кузнечиха районы коммунистларының район конференциясе 27 нче февральдә үзенең эшен тәмамлады.

Конференция райкомның эшен канәгатьләнерлек дип тапты.

Ябык (яшерен) тавыш бирү тәртибендә райком пленумы составына 25 член, 7 кандидат, 5 кешедән ревкомиссия сайланды. Партиянең өлкә конференциясенә делегатлар сайланды. (ТатТАСС).

НОРЛАТ РАЙОНЫНДА

(Телефон буенча)

28 нче февральдә Норлат район коммунистларының конференциясе эшли башлады. Райком секретаре иптәш Школдовның отчет-докладыннан соң фикер алышуларда катнашкан иптәшләр соңгы елларда районда иген уңышының кимегәнлегенә аеруча тукталдылар. Мәсәлән, 1937 нче елны һәр гектардан 15,48 центнер иген уңышы алынса, 1938 нче елны һәр гектардан уңыш алу 8,72 центнерга, 1939 нчы елны 8,30 центнерга төшкән. Чөнки райкомның җитәкче работниклары ирешелгән уңышлар белән масаеп, югары уңыш өчен көрәшне йомшартканнар. Шуның нәтиҗәсендә, агротехника чараларын тормышка ашыру эше елдан-ел начарая барган. Үткән елны комбайн белән эшләү планы 49 процент һәм тракторлар белән эшләү планы 69 процент кына үтәлгән.

Иптәш Школдов үзенең отчет докладында карарларның үтәлеше һәм пленум членнарының эшләре турында бөтенләй тукталмады. 29 нчы февральдә отчет доклады буенча фикер алышулар барды.

Х. Хәлилев.

ЧИСТАЙ РАЙОНЫНДА

Чистай районы большевикларының конференциясе 4 көн дәвам итте һәм ул зур оешканлык, күтәренкелек белән барды. ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарларын тормышка ашыру өчен көрәшне тәэмин итмәүләре, кадрларга бюрократларча карараулары, массадан аерылулары, районда предприятиеләргә, авыл хуҗалыгына һәм башлангыч партоешмаларга начар җитәкчелек итүләре өчен, райком секретарьлары Әблялимев, Завьялов, Макрушин иптәшләрне делегатлар кыю рәвештә тәнкыйтьләделәр.

28 нче февральдә сайлаулар булды. Сайлаулар вактында Әблялимев, Завьялов иптәшләр списокка бөтенләй кертелмәделәр, ә Макрушин списоктан төшерелеп калдырылды. Ябык (яшерен) тавышка кую тәртибендә райком пленумы составына 35 член, 9 кандидат һәм ВКП(б) ның Татарстан өлкә конференциясенә тавыш бирү хокукы белән 9, киңәш бирү хокукы белән 3 делегат сайланды.

Кичә, пленум утырышында ВКП(б) райкомының беренче секретаре итеп Воробьев, икенче секретаре итеп Зарипов һәм өченче секретаре итеп Калмыков иптәшләр сайландылар.

К. Исламов.

КЫЗЫЛ ЮЛ РАЙОНЫНДА

27 нче февральдә Кызыл Юл коммунистларының район күләмендәге отчет-сайлау җыелышы ачылды. Җыелышка ВКП(б) членнарыннан 99, кандидатлардан 105 кеше катнаша. Җыелыш зур күтәренкелек белән ВКП(б) Үзәк Комитетының Политбюро членнарын почетлы президиумга сайлады.

Райкомның эше турында райком секретаре иптәш Махианов доклад ясады. Отчет чоры эчендә районда ВКП(б) членнарының саны 48 кешедән 121 гә, кандидатларның саны 41 кешедән 108 гә җиткән. Партиягә яңа алынучылар арасында: Хасан күле янындагы сугышларда катнашкан орденлы Шаһимәрдәнев, орденлы укытучы Фатыйма Садыйкова, „Аеруча хезмәт күрсәткән өчен" медале белән бүләкләнгән укытучы Шаһиева һ. б. иптәшләр бар.

Отчет-докладыннан соң фикер алышулар башланды. Җыелышның беренче утырышында Вафин (райкомол), Сонгатуллин (редакция), Галимҗанов (тулы булмаган урта мәктәп директоры) иптәшләр чыгып сөйләделәр. Алар районда агитация-пропаганда эшенең куелышы начар булуы турында, партиягә яңа кабул ителгән коммунистлар арасында эшнең җитәрлек булмавы турында сөйләделәр.

(ТатТАСС).

БИЛӘР РАЙОНЫНДА

27 нче февральдә партиянең район конференциясендә райком секретаре иптәш Вафинның отчет-доклады буенча фикер алышулар булды һәм 37 кеше чыгып сөйләде.

Фикер алышуларда чыгып сөйләгән Никонов, Зәйниев, Хафизов һәм башка иптәшләр, башлангыч партоешмаларга баргач, райком инструкторларының барыннан да бигрәк хуҗалык мәсьәләләре белән шөгыльләнүләре, партия эшенә әһәмият бирмәүләре турында сөйләделәр. Бабушкин, Насыйбуллин һәм Сократов иптәшләр яшь кадрларны тәрбияләү эшенең куелышы йомшак булуын күрсәтеп үттеләр.

Биләр авыл советы башкарма комитеты председателе иптәш Федотов Биләр МТС ының язгы чәчүгә начар хәзерләнүе турында сөйләде. Тракторларга ремонт ясау тәмамланмаган, газогенераторлы тракторлар өчен утын хәзерләнмәгән, ә райком бу мәсьәләгә бик аз игтибар бирә.

(ТатТАСС).

АПАС РАЙОНЫНДА

Партиянең Апас район конференциясе өченче көн дәвам итә. Конференциягә тавыш бирү хокукы белән 65, киңәш бирү хокукы белән 22 делегат катнаша. Делегатларның күпчелеге яшь кадрлар, районның иң яхшы кешеләре.

Райком секретаре иптәш Хәйруллин отчет-доклады ясады. Фикер алышуларга язылган 39 делегаттан 28 кеше чыгып сөйләде. Алар райкомның эшен кискен рәвештә тәнкыйтьләделәр, ялгышларын, җитешсезлекләрен кыю рәвештә ачып салдылар. Райком секретарьларының һәм инструкторларының башлангыч партоешмалар белән бәйләнешләре начар булуын күрсәттеләр.

(ТатТАСС).

ЗАИНСКИЙ РАЙОНЫНДА

28 нче февральдә партиянең Заинский район конференциясе ачылды. Конференциягә тавыш бирү хокукы белән 68 һәм киңәш бирү хокукы белән 20 делегат катнаша.

ВКП(б) райкомы секретаре иптәш Иванов отчет доклады ясады. Отчет чоры эчендә партия сафларына 73 член, 139 кандидат кабул ителде. Районда 500 дән артык кеше „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н үзлегеннән һәм түгәрәкләрдә өйрәнә. Алар өчен 21 лекция, 55 тапкыр группалы һәм индивидуаль консультация, 3 теоретик конференция, 21 тапкыр иптәшләрчә беседа үткәрелде.

Кайбер коммунистлар, бигрәк тә җаваплы работниклар, шул исәптән Чыбыклы МТС ы директоры Хәлиуллин, райсовет башкарма комитеты председателе Сахапов, „Красный Зай" газетасы редакторының урынбасары Батьков, Дәүләт банкысы бүлегенең управляющие Килзев иптәшләр „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н өйрәнүгә керешмәгәннәр. Башлангыч партоешмаларга һәм ялгыз коммунистларга райкомның ярдәме җитәрлек түгел.

29 нчы февральдә отчет-докладыбуенча фикер алышулар башланды. (ТатТАСС).

МАТБУГАТ КҮЗӘТҮ УРНЫНДА

Газета культуралы итеп эшләнергә тиеш

„Агач яисә металл буенча токарь шикелле үк, литератор да үз материалын—телне, сүзне яхшы белергә тиеш" (М. Горький).

Максим Горькийның бу сүзләре журналистларга нык кагыла. Ләкин матбугат работниклары арасында бу әһәмиятле мәсьәләгә тиешле бәяне биреп җиткермәүчеләр аз түгел әле.

Кайбер район газеталарында тел кытыршылыгы, культурасызлык, җөмләләрне озын һәм аңлаешсыз итеп төзү, иң элементарь сүзләрне дә дөрес яза белмәү һәм даталарны бутау фактлары еш кына очрый.

Без монда **„Коммунизмга"** (Ютазы районы) һәм „Тоташ колхоз" (Шөгер районы) газеталарын мисаль итеп алабыз. Бу газеталарның икесендә дә стиль һәм тел мәсьәләсендә зур кимчелекләр бар. Алар урнаштырыла торган материалларны яхшы итеп эшләүгә игтибар биреп җиткермиләр. Аңлашылмый торган, буталчык җөмләләрне бу газеталарның һәрбер номерында очратырга мөмкин.

Мәсәлән, „Коммунизмга" газетасының узган ел 12 нче декабрьдә чыккан номерында „Хәл иткеч ай" дигән хәбәр урнаштырылган. Аның кайбер җөмләләрендә сүзнең нәрсә турында баруын да аңлавы кыен. „Мәҗбүри җыемнарны срогында җыеп алуда кайбер авыл советы җитәкчеләренең хезмәт ияләре арасында масса аңлату эшләрен тиешенчә җәелдерелмәгәнлектән килә" дигән җөмлә аңлашылмый. Редактор урынбасары иптәш С. Әхметҗанов (бу номер аның имзасы белән чыккан) монда нәрсә әйтергә теләгәндер. Хәбәрнең „Шуларның барсын хисапка алган акча туплауның срогында үтәлмәвеннән, хезмәт ияләренең көнкүрешен тагын да яхшырту, уку-укыту эшләрен тиешле югарылыкка күтәрү, сәламәтлек саклау һәм авыл хуҗалыгына бәйләнгән күп кенә эшләрне тиешенчә куя алмауга алып бара" дигән җөмләсеннән дә сүзнең нәрсә турында баруын аңлап булмый.

„Тоташ колхоз" газетасының (№60) баш мәкаләсендә: „Терлекчелекнең яңа үсешенә ирешүдә—яңа фермалар булдыру, булган фермаларны тиешле санга кадәр үстерү һәм типовой тораклар белән аларны тәэмин итүдәге, моңа кадәр булган ялгыш карашлар ашыгыч бетерелергә тиеш" диелә. Сүзләр арасындагы бәйләнеш дөрес булмаганлыктан, „ялгыш карашлар" ның нәрсәләргә кайтып калуы аңлашылмый һәм ялгыш мәгънә аңлауга юл кала.

Шул ук газетаның 62 нче номерындагы баш мәкаләсендә: „Юлтимер авылында положение өйрәнү занятиеләрен иптәш Әсәдуллин 9 мәртәбә, иптәш Газизов 7 мәртәбә һәм тагын күп кенә агитаторлар байтак мәртәбәләр югары сыйфатлы итеп үткәрелделәр инде" диелгән. Бу җөмләнең эшләнеп җитмәгәнлеге ачык күренеп тора.

Мондый буталчык җөмләләр кечкенә хәбәрләрдә дә еш очрыйлар. „Санитария-оборона эшен яхшыртырга" дигән хәбәрдә („Коммунизмга", № 78) „... ничә башлангыч оешмасы, ничә кеше член булуы турында һәм шулай ук акча эшләре дә дөрес хисап алып барылмаган" дигән җөмлә үзе генә дә моны раслый. Шул ук газетаның 79 нчы номерында иптәш Сәитова хәбәрендә „...бүлмәләре, естәл, урындыклар ягу-яктырту әйберләре һәммәсе хәзер" дигән җөмләдә „урындыклар ягу-яктырту" дигән мәгънә килеп чыккан.

Татар теленең үзенчәлекләрен һәм җөмлә төзелеше кагыйдәләрен белмәү нәтиҗәсендә килеп чыккан мондый ялгышлар бик күп.

„Соңгы 3 елда уртача һәр гектардан 12 центнер уңыш алынды" дигән җөмлә, нининдер уртача гектар булуын, гектардан 3 елга 12 центнер гына уңыш алынуын анлата. Фактта исә, колхоз гектардан 3 елга 12 центнер түгел, бәлки 36 центнер, ягни һәр гектардан елына уртача 12 центнер уңыш алган. Хәбәрдә әнә шуны әйтергә кирәк иде. „Алар сайлаучыларның белешмәләренә җавап бирәләр", „сайлау участкысы члены", „берләшкән терлекләрнең", „щитаны чыбыктан һәм тактадан 2 метр буе, 1 метр иңенә ясарга кирәк" („Коммунизмга"); „Барлык колхозчыларны да яңа алфавитны өйрәтеп бетерү", „яшен яңгырлары аркылы", „хезмәт көннәре булучы колхозчылар" („Тоташ колхоз") кебек ялгыш төзелгән җөмләләр бу газета работникларының тел һәм стиль мәсьәләсенә игтибарсыз карауларын күрсәтәләр.

Хәбәрне эшләгәндә фактларны туплау гына җитми, аларны хәбәрдә бәйләнешле итеп урнаштыруга һәм җөмлә төзелешенә нык игтибар бирергә кирәк.

Бу газеталарда политик яктан тупас ялгыш җибәрү, әһәмиятле даталарны бутау фактлары да бар. Мәсәлән, „Коммунизмга" газетасының 18 нче декабрь номерында „Халыкларның бөек юлбашчысы" дигән мәкаләдә политик ялгыш җибәрелгән. „Сталин исмен югары тотарбыз" дигән хәбәрдә колхозчы—ударникларның беренче Бөтенсоюз съездының датасы 1933 нче ел урнына 1932 нче ел булып киткән. „Осоавиахим оешмасы яхшы эшли" (№ 80) дигән хәбәрдә „Кызыл Армиянең XXII нче еллыгы" дип әйтәсе урынга „XXI еллыгы..." дип киткән.

„Тоташ колхоз" газетасының (№60) суд турындагы хәбәрен алып карыйк: „Алар һәр кайсы, суд карары нигезендә алимент түләүдән баш тартып йөрүләре өчен бер ел да 6 шар айга ирекләреннән мәхрүм ителделәр" диелә хәбәрдә. Алимент түләргә тиешле кешеләргә суд мондый нигез бирмәгәндер, әлбәттә. Хәбәрне: „Судның алимент түләтү турындагы карарыннан баш тартулары өчен алар бер ел да 6 айга ирекләреннән мәхрүм ителделәр" дип язарга кирәк иде. Шулай булмаганда, халык судын гаепләү килеп чыга.

Бу газеталар кирәкмәгән урында рус сүзләрен еш кулланалар. Мәсәлән: войскасы, конюхлар, РИК, дворларга, кормы, публиканың, кружокта, ит поставкалары кебек сүзләр „Коммунизмга" газетасы битләрендә күп очрый. Рус һәм чит ил телләреннән кергән сүзләр күп урыннарда бозып язылалар: „президюмга", „устафы", „афторитет", „лозонгысы", „сругында", „мибелләр", „учутка", „дериктива", „перепесчиклар", „пролетарият", „делигаты", „музика", „градост" („Коммунизмга" газетасы); „Бюджед", „Октябряд", „кондидат" („Тоташ колхоз" газетасы).

Рус графикасы нигезендә яңа алфавитны үзләштерү эше дә аксый. Мәсәлән, „Терентий", „Кыям", „материаль ярдәм", „бигрәк тә" дигән сүзләр һәм исемнәр „Теренти", „Къям", „материал ярдәм", „бикрәк тә" дип язылганнар („Тоташ колхоз").

Җөмләдә бер генә дә артык сүз булмаска тиеш. Ә бу газеталар моңа „юмартлык" күрсәтәләр. „Тоташ колхоз" дан бер генә факт китерик. Г. Вайцеховскийның „Мин эшләгән округта" дигән хәбәре „Мин—Вайцеховский Г..." дип башланып китә. Үз имзасы белән чыккач, хәбәрне аның исеме белән башлап китү нәрсәгә кирәк?

Тыныш билгеләрен дөрес куймау, аерым языла торган сүзләрне кушып, ә бергә языла торган сүзләрне аерып язу фактлары да күп. Аларга аерым тукталып тормыйбыз.

„Коммунизмга" газетасы редакторы Зиннәтуллин һәм „Тоташ колхоз" газетасы редакторы М. Шарипов иптәшләр бу кимчелекләрне бетерү һәм газеталарның сыйфатын яхшырту турында конкрет чаралар күрерләр.

Г. Сафиуллин.
Н. Мансуров.

КАЗАНДА ФУКО МАЯТНИГЫ

1851 нче елда, француз физигы Фуко Парижда маятник белән тәҗрибә ясаган. Бу тәҗрибә җирнең үз күчәре тирәсендә тәүлек буена әйләнүен бәхәсләргә урын калдырмаслык итеп, күргәзмә рәвештә исбат иткән. Фуко, Пантеонның биек гөмбәзенә беркетелгән 68 метрлы корыч чыбыкка 30 килограмм авырлыгындагы бакыр шар аскан. Бу маятник бер яктан икенче якка хәрәкәт иткәндә идәнгә сибелгән вак ком катлавында эзләр калдырган. Ләкин маятникның бер генә линия сызмаганлыгы, ә урталыктан бер-берсен аркылыга кыйгач кисеп үтә торган бик күп туры сызыклар сызуы билгеле булган. Бу хәл маятникның хәрәкәт тигезлеге бер якка тайпылуын, яки көнчыгыштан көнбатышка таба әйләнүен күрсәтә.

Маятникның башлангыч юнәлешеннән тайпылуын нәрсә белән аңлатырга соң? Маятникның хәрәкәт тигезлеге үзгәрә алмый икәнлеге исбат ителгән нәрсә. Шунлыктан, Фуко маятнигы да башта кайсы юнәлештә җибәрелгән булса һәр вакыт шул ук юнәлештә хәрәкәт итәргә тиеш. Һәм әгәр дә, маятник үзенең башлангыч юнәлешеннән туктаусыз рәвештә тайпыла икән, бу инде үзенең хәрәкәт тигезлеге юнәлешен саклаучы маятникка чагыштырма рәвештә бөтен җир белән бергә бинаның һәм аның идәненең дә әйләнгәнлегеннән килә. Димәк, бу тәҗрибә, җирнең үз күчәре тирәсендә әйләнеп хәрәкәт итүен турыдан-туры күргәзмә рәвештә исбат итә.

Фуко тәҗрибәсен кабатлап карау, узган гасырның 80 нче елларында Петербург университеты бинасында, 90 нчы елларның башында Рига шәһәрендә, 1901 нче елда яңадан Петербург шәһәрендә булды. Чама белән 900 нчы елларда, ул вакытта герләр һәм үлчәүләр палатасы управляющие булып эшләгән бөек рус химигы Д. И. Менделеев маятник белән тәҗрибә ясады. Шул ук елларда Фуко тәҗрибәсе Кронштадтта кабатланды.

Революциягә кадәрге Россиядә Фуко тәҗрибәсен кабатлап карау турында шуннан башка әйтерлек нәрсә эшләнмәде.

Фуко маятнигы белән тәҗрибә ясау, ягни җирнең тәүлек буена әйләнүен гади итеп һәм күргәзмә рәвештә исбат итү, массаларны дингә каршы рухта тәрбияләүдә аны чын фәнни корал итү бары тик Советлар власте шартларында гына мөмкин булды.

Советлар Союзында даими эшләп торучы Фуко маятнигы иң беренче буларак, Сугышчан Алласызлар Союзының Ленинград Өлкә Советы тарафыннан булдырылды. 1931 нче елның 20 нче мартында Ленинградтагы дингә каршы музейдә (элекке Исакиевский соборында) профессор Н. Т. Каменщиков тәкъдиме буенча Фуко тәҗрибәсе күрсәтелде. Соборның баш гөмбәзенең гаять зур эчке биеклеге маятник өчен тулысынча файдаланылды. Бу биеклек 101 метр 98 сантиметр тәшкил итә. Шунлыктан анда маятникны 93 метр озынлыкта итеп эшләргә мөмкин булды.

Казанда Фуко маятнигын төзү эше ТАССР ның крайны өйрәнү Үзәк Музееның дингә каршы бүлеге һәм Сугышчан Алласызлар Союзының Республика Советы работниклары инициативасы белән башланды. Бу эш Казан Дәүләт университетының фәнни работниклары көче белән университетның физика кафедрасы мөдире, профессор Е. К. Завойский җитәкчелегендә алып барылды. Маятникны төзү һәм җиһазлау эшендә ассистент Г. М. Кочергин һәм галим механик Н. В. Калагуров иптәшләр турыдан-туры катнаштылар.

Бу маятник ТАССР ның дингә каршы музеенда (элекке Петропавловский соборында) эшләнде. Монда биеклек 30 метр һәм шул биеклектә диаметры 4 миллиметрлы корыч чыбыкка 54 килограмм авырлыгында кургаш шар тагылды. Корыч чыбыкның югарыга беркетелгән урны собор үзе җир белән бергә әйләнгәндә чыбыкның бөтерелүен киметерлек итеп һәм шуның белән маятникка үзенең башлангыч хәрәкәт юнәлешеннән тайпылмаска мөмкинлек бирерлек итеп шарикоподшипниклар куеп эшләнде. Маятникның күренгән тайпылышын күзәтеп һәм теркәп бару өчен аста диаметры 4 метр булган түгәрәк мәйдан эшләнде. Бу мәйдан 360 градуска бүленгән. Алар, Казан шәһәре урнашкан географик киңлеккә (Казан урнашкан киңлек 55 градус, 47 минут) карап, Фуко формуласы буенча маятникның тайпылышын исәпләргә ярдәм итәләр. Фуко маятнигының моделе һәм маятникны хәрәкәткә китерү эше тулысынча механикалаштырылган.

Маятник урнашкан залда „Дөньяның яратылышы һәм үсүе турында фән һәм дин" дигән темада зур күргәзмә оештырылды. Маятник якын көннәрдә ачыла.

Зиннәт Мәҗитов.

ТАССР ның дингә каршы музеенең өлкән фәнни сотрудниги.

Газета үзенең кем органы икәнен дөрес язарга тиеш

Безнең алдыбызда район газеталарының февраль аенда чыккан яңа номерлары. Аларны карагач та, газетаның органы турындагы билгеләрнең төрлелеге һәм ялгыш язылулары күренә.

Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулардан соң шактый вакыт үтсә дә, „Колхоз байрагы" газетасы—ТАССР, ВКП(б) ның Саба район комитеты һәм район башкарма комитеты органы дип, элеккечә язуда дәвам итә. Алабуга, Актаныш район газеталары да шулай язалар. „Яңа тормыш" газетасы үзен—„ВКП(б) ның Арча райкомы һәм райсовет органы дип; „Коммуна"—Азнакай, ВКП(б) райкомы, район советы башкарма комитеты органы дип; „Ленин юлы"—„ВКП(б) ның Әгерҗе райкомы һәм хезмәт ияләре депутатларының район советы башкарма комитеты газетасы, дип язалар. „Социализмга" газетасы—ВКП(б) ның Әлмәт райкомы һәм хезмәт ияләре депутатларының Әлмәт район башкарма комитеты органы дип, уздырып та җибәргән.

Буденный, Сарман, Балык Бистәсе, Мамадыш, Минзәлә һәм тагын берничә район газетасы гына үзләренең кем органы булуларын дөрес итеп язганнар. Мәсәлән, „Буденныйчы" газетасы—„ВКП(б) ның Буденный райкомы һәм хезмәт ияләре депутатларының район Советы органы" дип яза. Безнеңчә, әнә шулай язарга кирәк.

Г. Кәбиров.

Кызыл Армиянең XXII еллыгы уңае белән оештырылган чаңгы ярышына катнашучылардан (Казан Дәүләт университеты укучылары)—сулдан уңга—Т. Рагузина, Л. Гладишева, Н. Бадулина иптәшләр. И. Галиев фотосы.

Җәнлек асраучылык совхозында

Чистай районындагы җәнлек асраучылык совхозының куянчылык фермасы яхшы нәселле куяннар асрау белән танылган ферма. Соңгы 3 ел эчендә Чкалов, Чиләбе, Киров өлкәләренә, Башкыртстан республикасына һәм республикабызның күп кенә колхозларына, совхозларына фермадан „Венский" һәм „Ангар" нәселле 16 мең баш куян сатылган. Фермадан сатылган куяннарның күп үрчүчән һәм мул продукция бирүчән булулары турында күп кенә урыннардан һәр вакыт хатлар килеп тора.

Фермада үткән ел 678 баш куяннан 13.639 баш куян алып үстерелде. Аерым куяннар тагын да күбрәк үрчем бирделәр. Мәсәлән, „Ангар" нәселле 392 нче номерлы куян елга 6 тапкыр балалап, һәрберсендә 6 шар бала китерде. „Венский" нәселле 129 нчы номерлы куян ел саен 35—36 бала китерә. Бу куянның авырлыгы 4,2 килограмм тарта. Мондый күп үрчем бирүче куяннар хәзер фермада күпләп санала.

Бу ферма 1939 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашып Күргәзмә Комитеты тарафыннан икенче дәрәҗә диплом, 5 мең сум акча һәм мотоцикл белән бүләкләнде. Ферма 1940 нчы елда да күргәзмәгә катнашуга кандидат итеп расланды.

К. Исламов.

КОЛХОЗ АПТЕЧКАЛАРЫ

Язгы чәчү кампаниясе уңае белән авылга дарулар җибәрү көчәйтелде.

Татарстан Аптекалар Идарәсе колхозлар, совхозлар һәм МТС лар өчен 10 мең данә аптечка хәзерли. Аптечкаларны районнарга җибәрү башланды инде. Шуның өстенә колхоз һәм совхоз ясләләре өчен 1.450 аптечка җибәрелә.

Аптечкаларны район аптекаларыннан алырга мөмкин.

Терлекчелекне үстерү өчен кредитлар

Колхозларда терлекчелекне үстерү өчен дәүләт тарафыннан ел саен зур сумалар бирелеп килә.

Узган ел Татарстан колхозларындагы терлекчелек фермаларында силос башнялары һәм терлек абзарлары төзү өчен дәүләт тарафыннан 2 миллион 231 мең сум кредит билгеләнгән иде. Ләкин терлекчелекне үстерү эшенә күп кенә район җир бүлекләренең һәм колхоз правлениеләренең җитәрлек әһәмият бирмәүләре нәтиҗәсендә, бу кредит тулысынча файдаланылмады.

Татнаркомземга алынган мәгълүматларга караганда, колхозлар терлекчелек фермаларында яңа төзү эшләре өчен 1 миллион 730 мең сум гына кредит алганнар. 1940 нчы елның беренче кварталында бу эшкә 351 мең сум кредит билгеләнде. Барлык районнарда кредитлардан тулысынча файдаланырга, терлекчелек фермаларында узган елларда башланган төзелешләрне кичекмәстән тәгәлләргә һәм яңа төзелешләр өчен төзү материалларын кыштан ук хәзерләп куярга кирәк.

АРТИСТЛАР МОПР ОЕШМАСЫНЫҢ АКТИВИСТЛАРЫ

Татарстан Дәүләт филармониясе янындагы МОПР ячейкасы яхшы гына эшләп килә. Масса арасында интернациональ тәрбия эшләрен яхшы кую нәтиҗәсендә коллективның барлык работниклары да МОПР сафында член булып торалар. МОПР членнарының инициативасы белән 1939 нчы елда интернациональ кичә үткәрелде һәм аннан җыелган 800 сум акча МОПР фондына күчерелде.

Ячейка хәзер 18 нче март—МОПР көненә хәзерләнә. Татар Дәүләт Академия театры, Зур Драма театры, Татар Дәүләт Опера театры һәм Казан Дәүләт Циркы янындагы МОПР оешмаларын филармония МОПР ячейкасы социалистик ярышка чакырды.

Т. Садыйков.

Татарстанда

— Алабуга районындагы педучилищедә мотоцикл моторын өйрәнү түгәрәге оештырылды. Бу түгәрәк укучылар арасында зур кызыксыну тудырды. Түгәрәккә допризывниклардан 11 кеше йөри.

— Кызыл Юл районы, Яңа Кенәр урта мәктәбенең Осоавиахим оешмасында 110 кеше член булып тора. ПВХО, „Ворошиловча атучы", БГТО, БГСО түгәрәкләре системалы рәвештә эшлиләр. Соңгы вакытта 33 кеше оборона значокларына нормалар тапшырдылар.

ЯШЬЛӘР ТРАКТОРНЫ ӨЙРӘНӘЛӘР

Кызыл Армия районының комсомолецлары һәм союздан тыш яшьләр тракторны өйрәнүгә зур игътибар бирәләр. Каргалы МТС ы янында оештырылган тракторчылар курсында 47 кеше укый, аларның 18 е хатын-кызлар. Тат. Ялтан МТС ы янындагы курсларда 71 укучының 13 е хатын-кызлар.

„Пятилетка", „Үрнәк", „Марс", Киров исемендәге, Ворошилов исемендәге һәм Карл Маркс исемендәге колхозларда да 137 кеше (47 се хатын-кызлар) производстводан аерылмыйча тракторны өйрәнәләр. Бу колхозларның партия һәм комсомол оешмалары бу эшкә зур ярдәм күрсәтәләр.

Кайбыч районының Борындык авылында хатын-кызлардан тракторчылар хәзерләү курслары оештырылды. Анда 25 хатын-кыз укый. Курсларга Мөрәле МТС ының тракторчысы иптәш А. Сафин җитәкчелек итә. Курсантлар занятиеләргә зур әһәмият биреп йөриләр. Алар быел курсларны тәмам итәчәкләр.

ДОХОД БҮЛҮ

Буа районының „Искра" колхозында доход бүлү үткәрелде. Колхозчылар һәр хезмәт көненә 3,1 кило бөртекле ашлык һәм бер кило яшелчә алдылар.

Колхозның алдынгысы—стахановчы иптәш Фәсхеттинев Б. семьясе хезмәт көннәре өчен 237 пот бөртекле ашлык, 309 сум акча, иптәш Әхмәтҗанов Х. семьясе 217 пот ашлык һәм 303 сум акча алдылар.

„Искра" колхозы орлыкларны чистарту һәм авыл хуҗалыгы машиналарына, инвентарьларына ремонт ясау эшләрен төгәлләде инде.

Колхозчылар өчен агроукулар оештырылды. Занятиеләрне агротехник иптәш Вәлиев үткәрә.

Шулай да „Искра" колхозында әле чәчүгә хәзерлектә шактый кимчелекләр бар. Кар тоту планы бары 56,4 процент, тирес чыгару планы 55,3 процент кына үтәлгән. Бу колхозда 6 кырчылык бригадасының тик беренче номерлы бригадасында гына даими звенолар төзелгән.

И. Ильясов.

УМАРТАЧЫЛЫКТАН МУЛ ПРОДУКЦИЯ

Безнең колхоз умартачылыктан ел саен күп бал ала. 1938 нче елда һәр умартадан уртача 32,5 килограмм бал алынган иде. Үткән ел һәр умартадан 38 килограмм бал алынды һәм 170 семья корт 208 семьяга җиткерелде. Билгеле, безнең 47 хуҗалыклы колхоз өчен бу зур байлык.

Бездә кортлар табигый чәчәкләрдән генә файдаланалар. Бу гына җитми, колхоз басуында кортлар бал җыя торган үләннәр чәчәргә кирәк. Ләкин район җир бүлеге безнең колхозга чәчү планы җиткергәндә кортлар бал җыя торган үләннәр чәчүне планнан ел саен төшереп калдыра иде. Бу безнең умарталардан бал алуны түбәнәйтте. Быел бөртекле культуралар мәйданын планлаштырганда колхоз бу моментны истә тотарга тиеш.

Ә. Сираҗиев.

Кузнечиха районының „Ирек" колхозы умартачысы.

ШАХМАТ-ШАШКА

1 нче мартта Казан беренчелеге өчен шахмат-шашка командалары ярышының икенче туры була.

Ярышларга шәһәрнең 11 шахмат һәм 8 шашка командасы катнаша. Катнашучылар арасында 17 яшьлек Авакомов, 18 яшьлек Ждярский һәм Вельтмандер иптәшләр белән бер рәттән — укытучылардан Миллер, һәм Радзивилко, ассистентлардан Медведев һәм Еремин, доцент Морозов, профессор И. Д. Адо һ. б. иптәшләр бар.

24 нче февральдә булган беренче турда „Темп" (КИИКС) спорт җәмгыяте вәкилләре—доцент Морозов һәм студент Акбулатов иптәшләр гүзәл нәтиҗәләргә ирештеләр. Иптәш Морозов „Спартак" спорт җәмгыяте вәкиле—беренче категорияле шахматчы Кильматовны, ә иптәш Акбулатов Казан шәһәренең иң карт шахматчыларыннан Косолаповны отты. Ләкин „Спартак" командасы составының тигез көчле булуы аңа гомуми отышны тәэмин итте. Очрашу 6 1/2: 3 1/2 исәбе белән „Спартак" файдасына тәмам булды. „Наука" спорт җәмгыятенең көчле командасы „Большевик" җәмгыяте командасын зур исәп белән (10:1) отты, „Крылья Советов" командасы да зооветеринария институты командасын 10 1/2: 1/2 исәбе белән җиңел рәвештә отты. „Буревестник" командасы „Медик" командасына оттырды (3 1/2 :7 1/2). 2 нче турда Укытучылар йортында „Учитель" спорт җәмгыяте командасы „Крылья Советов" командасы белән очраша. „Учитель" җәмгыяте командасының беренче тактасында СССР шахмат мастерлыгына кандидат Рәшит иптәш Нәҗметдинов уйнаячак. Татпромсоветта „Спартак" һәм „Медик" командалары очрашачак. Бүген „Буревестник"—„Темп", „Большевик"—„Пролетарская победа" командалары да очрашырга тиешләр.

(ТатТАСС).

СУД
МУНЧА КАРАКЛАРЫ

Шәһәрнең мунчалар һәм кер юу урыннары тресты мунчаларга юынырга керүчеләрнең киемнәрен саклауга җитәрлек игътибар бирми. Шунлыктан мунчаларда кием урлану фактлары шактый еш очрый. Казанның 2 нче номерлы мунчасында соңгы 3 ай эчендә генә 22.000 сумлык киемнәр урланган.

Урлаучылардан кайберләре тотылып суд җаваплылыгына тартылганнар иде. Аларның эшләре Бауман районының 3 нче участкы халык судында каралды. Урлаучылардан В. П. Саргаев бер ел да 3 айга, Нури Гыйльметтинов, Задә Әхметов һәм Әхәт Могыйнев берәр елга ирекләреннән мәхрүм ителүгә хөкем ителделәр.

КӨНДӘЛЕК ВАКЫЙГАЛӘР

Аферистлар. Сүлтер станциясеннән Казанга килгән шофер Артемьев Бауман урамыннан барган вакытта акчалы бумажник тапкан. Шул арада аның янына билгесез бер кеше килеп: „Әйдә акчаны бүләбез" дигән. Алар шундагы бер ишек алдына кергәннәр. Акчаны бүлгән вакытта алар янына тагын бер кеше килеп Артемьевка: „Нигә минем акчаны алдың?" дигән һәм аны тентеп, 900 сум акчасын талап алган. Артемьев тавыш куптаргач, аферистларның берсе качып киткән. Акчаны талап алучы Мезенцев дигән кеше кулга алынган.

БЕЛДЕРҮ

2 нче март, кич 6 сәгаттә Партия Мәгърифәте йортында (Чернышевский урамы, 25) комсомолның шәһәр активы өчен лекция була. Тема: „Европада сугыш һәм капиталистик илләрнең эшчеләр сыйнфы. Коммунистик партияләрнең тактикасы".

Лектор иптәш Тимофеев.

Җаваплы редактор урынбасары И. ҮЗБЕКОВ.
Зам. ответ. редактора И. УЗБЕКОВ.

ГОСМУЗПРОКАТ
рояль һәм пианиноләр сатып ала һәм сата. Клавишлы музыка коралларын көйләү, ремонтлау, упаковкалау, күчерү һәм аларга экспертиза эшләре үти.
Гитара, мандолина, скрипка һәм башка төрле щепной музыка коралларын ремонтка ала.
Госмузпрокат Казанда һәм Татарстан республикасы районнарында прокатка музыка кораллары алучы учреждениеләргә, оешмаларга һәм граждannarга белдерә: прокатка алынган музыка коралы өчен тиешле прокат түләве буенча булган бурычлар 3 көн срок эчендә түләнмәсә,—прокатка бирелгән музыка кораллары алыначак. Контораның адресы: Казан, Пионер урамы, 10 (Бауман урамы ягыннан кереллә). Телефон 6—73. Контора иртән 8 сәгаттән көндезге 4 кә кадәр эшли. 326—2—1

ТАТНАРКОМЛЕС
Чернышевский урамындагы 2 нче йорттан Толстой (элекке Подлужный) урамындагы 41 нче йортка, Сал Агызу һәм Урман эшләре институты бинасына
КҮЧЕРЕЛДЕ. 374—2—1

Татар Дәүләт Опера театры түбәтәйләр, чулпылар, күн кәвешләр, каракульдән эшләнгән татар бүрекләре, ирләр һәм хатын-кызлар өчен эшләнгән кунычсыз киез итекләр һәм хатын-кызлар өчен эшләнгән чигүле читекләр сатып ала. Казан, Зур Галактионов урамы, 13. Телефон 29—04. 250—2—2

Казан Ветеринария техникумы студентларын урнаштыру өчен
БҮЛМӘЛӘР ҺӘМ ПОЧМАК — УРЫННАР КИРӘК —
Тәкъдимнәр өчен адрес: Телеграф тыкрыгы, 6-9. Телефон 24—44. 214—3—3

Барлык предприятиеләр һәм дәүләт учреждениеләре игътибарына!
Таттранспромсоюз президиумының 1940 нчы ел, 2 нче февраль карары һәм артель членнары гомуми җыелышының 1940 нчы ел, 5 нче февраль карары нигезендә, 1940 нчы ел, 1 нче февральдән
„ВПЕРЕД" ТРАНСПОРТ АРТЕЛЕ ЕЛГА АРЬЯГЫ ГУЖТРАНС АРТЕЛЕ БЕЛӘН КУШЫЛДЫ
Адрес: Ягодный бистәсе, Краснококшай урамы, 77. Телефон 26—33. 324—1

Татарстан АССР Осоавиахим Үзәк Советы
АВТОМӘКТӘБЕ
III нче класс шоферлар хәзерләү һәм III нче класс шоферлардан II нче класс шоферлар хәзерләү курсларына
УКУЧЫЛАР АЛА
Укучылар предприятиеләрдән бирелгән командировкалар белән алына.
Укулар 15 нче мартта башлана. Казан, Профсоюз урамы, 10/14. Телефон 25—43. 387—2—1

Машиналар төзү заводы
җиңел һәм йөк автомобильләре
САТЫП АЛА
41—54 һәм 16—22 телефоннары буенча яисә почта адресы буенча М. Ф. Шиховка мөрәҗәгать итәргә. 36 нчы почта бүлеге, почта ящиге 732. 373—5—1

Архитектура-планлаштыру — мастерскаясы —
(Чернышевский урамы 1, өченче кат, 36 нчы бүлмә)
китайский тушь, Рихтерский һәм башка төрле готовальняләр, шулай ук архитектура буенча китаплар һәм журналлар САТЫП АЛА. Бәяләре килешү буенча. 221—3—3

Татарстан АССР Совнаркомы янындагы Физкультура һәм Спорт Эшләре Комитеты Автомотоклубы янындагы
АВТОМӘКТӘП
III нче класс шоферлардан II нче һәм I нче класс шоферлар хәзерләү буенча
шушы ел, 5 нче марттан
КУРСЛАР АЧА
Шулай ук, III нче класс любитель шоферлар, профессионал шоферлар һәм газогенераторчылар хәзерләү группаларына
УКУЧЫЛАР АЛА
Укыту расходлары өчен түләү командировка биргән оешмалардан яисә укучының үзеннән алына. Башка шәһәрләрдән һәм урыннардан килүчеләргә тулай торакта урын бирелә. Казан, Куйбышев урамы, 1, Автомотоклубның укыту бүлеге. 386—2—2

Татарстан АССР Совнаркомы янындагы Автоуправление
АВТО МӘКТӘБЕ
производстводан аерып һәм аермыйча укытып газогенераторчы һәм бензинчы III нче класс шоферлар хәзерләү группасына, шулай ук III нче класс шоферлардан II һәм I нче класс шоферлар хәзерләү группаларына
УКУЧЫЛАР АЛА
Укучылар учреждение, оешма яисә предприятиеләрдән бирелгән командировкалар буенча, шулай ук индивидуаль тәртиптә дә алына. Казан, Свердлов урамы, 40. Телефон 9—86. 360—2—1

КАЗГОРСТРОЙНЫҢ
Труба-пич эшләре конторасы
1940 нчы елда төтен юлларын чистарту эшләре буенча барлык дәүләт оешмаларының һәм йорт управлениеләренең контора белән
ДОГОВОР ТӨЗҮЛӘРЕН СОРЫЙ
Контораның адресы: Казан, Островский урамы, 39/6. Телефон 24—89. 146—3—2

КИРӘК:
„Кызыл Шәрык" заводы идарәсенә ИКЕ МАШИНИСТКА. Хезмәт хакы эш башыннан түләнә. Казан, Пләтән урамы, 9, завод идарәсе. 383—1

Даими эшкә ФИНАНСИСТ, магазиннар һәм предприятиеләр өчен ӨЛКӘН БУХГАЛТЕРЛАР, ТОВАР ӘЙЛӘНЕШЕ РАСХОДЛАРЫ БУЕНЧА ЭКОНОМИСТ һәм БҮЛЕК ӨЧЕН БАШ БУХГАЛТЕР. Ягодный бистәсе, Базар мәйданы, Райпищеторг. 370—2—1

Укыту-Курслар комбинатына даими эшкә МАШИНИСТКА һәм ҖЫЕШТЫРУЧЫ. Хезмәт хакы килешү буенча. Казан, Карл Маркс урамы, 5. 392—1

3 нче Мех фабрикасына ӨЛКӘН БУХГАЛТЕР һәм ПРОИЗВОДСТВО БУХГАЛТЕРЫ. Хезмәт хакы килешү буенча. Казан, Зур Ямашев урамы, 75 (6 нчы маршрут трамвае). Баш бухгалтерга мөрәҗәгать итәргә. 393—1

Татарстан АССР Совнаркомы янындагы Юллар идарәсенә, районнарда эшләү өчен юлларда күперләр, һәм трубалар салу эшләре белән таныш БЕЛГЕЧ-ДЕСЯТНИКЛАР. Казан Париж Коммунасы урамы, 2. 231—2—2

„Главмука" ның Татарстан трестына (Казан, Бауман урамы 35/12) ЭЛЕКТРОМЕХАНИКЛАР, БАШ БУХГАЛТЕРЛАР, ШОФЕРЛАР, МАШИНИСТКАЛАР, ҖИТЕШТЕРҮ ЭШЛӘРЕ БУЕНЧА АГЕНТ, пар машиналары һәм „Дизель" двигательләре буенча МЕХАНИКЛАР. 259—2—2

Казан тимер юл буфетлары конторасына, урыннарда эшләү өчен, ӨЛКӘН БУХГАЛТЕРЛАР һәм ПЛАНОВИКЛАР. Шартлары турында сөйләшергә килү өчен адрес: Казан, Париж Коммунасы урамы, 16. 323—2—2

Завод хезмәткәрләрен һәм эшчеләрен урнаштыру өчен 5—6 ай срок белән
квартиралар, бүлмәләр һәм почмак урыннар
— КИРӘК —
Казан, Островский урамы, 8, 16 нчы квартира. Ял көннәреннән башка һәр көн көндез 10 сәгаттән 3 кә кадәр, Ф. Г. Асафовка мөрәҗәгать итәргә. 384—3—2

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген һәм һәр көн
РСФСР ның атказанган артисты орденлы
М. ЗОЛЛО
гастрольләре
Яңартылган репертуарда көлке номер:
„МӘЕТ КҮМҮ"
хайваннар һәм кошлар башкаруында һәм башка номерлар.
1 нче мартта көндез 12 сәгаттә зур программа буенча
КӨНДЕЗГЕ ЦИРК УЕНЫ
Билетлар түбәнәйтелгән бәядән.
ЗОЛЛО ТИМЕР ЮЛЫ хәзерләнә.
Уен кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 3 кә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ачык.

Татарстан АССР Совнаркомы янындагы Физкультура һәм Спорт Эшләре Комитетына караган
АВТОМОТОКЛУБ
афтомобиль төзелеше
— теориясе буенча, —
любитель шоферлар өчен, беренче тапкыр
читтән торып уку курслары ача
Автомобиль төзелеше теориясен өйрәнү буенча читтән торып укучы любитель шоферлар Автомотоклуб автомашиналарында яисә любитель шоферларны читтән торып укыту буенча договор төзегән оешмаларның автомашиналарында, машина йөртү практикалары да үтәләр.
Барлык белешмәләр Автомотоклубның укыту бүлегендә бирелә. Куйбышев урамы, 1. 500—1

КАЗГОРЖИЛСНАБ
клиентларына тәкъдим итә:
булган нарядлар буенча Волгада водозабор янындагы һәм Ослан тавы буендагы
складлардан
бүрәнәләрне
сигезенче мартка
кадәр ташып
бетерергә.
Күрсәтелгән сроктан соң нарядлар бетерелә һәм алар буенча һичбер нинди дәгъвалар кабул ителмәячәк. 371—1

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
Бүген, 1 нче мартта
БУЛАК АРТЫ „РЕСПУБЛИКАСЫ"
Талон 125.
2 нче мартта КҮЗЛӘР (талон 126).
5 нче мартта ШӘМСЕКАМӘР (талон 127).
Спектакль кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
1 нче мартта көндез 12 сәгаттә (талон 23), шулай ук 2, 3 һәм 4 нче мартта
ЛЕНИН
Бүген кич
МАСКАРАД
(талон 113).
2 нче мартта талоннар белән кертелми.
3 нче мартта талон 114.
Коллектив рәвештә килү өчен заявкалар алына. Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП
„УНИОН" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ДУСЛАР
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 6, 8 һәм 10 да	ПАТРИОТ
„ЧАТКЫ" 6, 8, 9-30 да.	ЧЫҢГЫЗ ХАН НӘСЕЛЕ
„ПИОНЕР" 10-40, 1, 2, 3-30, 5-30, 7-10, 8-50, 10-30 да.	БЕТХОВИН КОНЦЕРТЫ Көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яшьтәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник" 6, 8 һәм 10 да.	УКЫТУЧЫ
„РОТ-ФРОНТ" 4, 6, 8, 10 да.	БАЛТЫЙКЧЫЛАР
КУЛЬТУРА САРАЕ 4-30, 7, 9 да.	МИНИН ҺӘМ ПОЖАРСКИЙ

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 734 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА. ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 829.